РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.03.2019 Олы Кайбыч авылы № 19

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында терроризм һәм экстремизмга каршы тору буенча мәгълүмат-пропаганда эше алып баручы антитеррористик комиссия эшче төркеме төзү турында**

Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2018нче елның 28нче декабрендә расланган Пр-2665 номерлы Россия Федерациясендә 2019-2023нче елларга терроризм идеологиясенә каршы тору Комплекслы планын гамәлгә ашыру һәм халыкның аерым катлауларына юнәлтелгән терроризм һәм экстремизм профилактикасы буенча мәгълүмат-пропаганда эше мәсьәләләрен чишү максатында, шулай ук 2009нчы елның 5нче октябрендәге Россия Федерациясендә терроризмга каршы тору Концепциясе һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005нче елның 27нче августындагы 1314-Р номерлы Күрсәтмәсе нигезендә,

**КАРАР КЫЛАМ:**

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында терроризм һәм экстремизмга каршы тору буенча мәгълүмат-пропаганда эше алып баручы антитеррористик комиссия эшче төркеме турында Нигезләмәне расларга (Кушымта №1).
2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында терроризм һәм экстремизмга каршы тору буенча мәгълүмат-пропаганда эше алып баручы антитеррористик комиссия эшче төркеме составын расларга (Кушымта №2).
3. Район Башлыгының 2015нче елның 29нчы декабрендә чыккан 66нчы номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында терро-ризм һәм экстремизмга каршы тору буенча мәгълүмат-пропаганда эше алып баручы антитеррористик комиссия эшче төркеме төзү һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендәге тормыш эшчәнлеге объектларын тикшерү, тормыш эшчәнлеге объектлары исемлеген раслау турында» (2017нче елның 15нче февралендә 17нче номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) карарын гамәлдән чыккан дип санарга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольләүне үз өстемдә калдырам.

**А.И.Рәхмәтуллин**

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Башлыгының
2019е. «15» мартында чыккан
19 номерлы карарына
кушымта № 1

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында терроризм һәм экстремизмга каршы тору буенча мәгълүмат-пропаганда эше алып баручы антитеррористик комиссия эшче төркеме турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

1.Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында терроризм һәм экстремизмга каршы тору буенча мәгълүмат-пропаганда эше алып баручы антитеррористик комиссия эшче төркеме максатларын, бурычларын һәм эшчәнлек тәртибен билгели.

2. Үз эшчәнлегендә эшче төркем Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Милли антитеррорис-тик комитеты һәм Антитеррористик комиссия карарларына таяна.

3. Эшче төркем Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында терроризмны кисәтү өлкәсендә мәгълүматый сәясәтнең халыкның категориясен билгеләү, терроризм һәм экстремизмны кисәтү белән бәйле хәлләрдә оператив мәгълүматый җавапчанлыкны тормышка ашыру форма-лары һәм методларының төп юнәлешләрен билгеләү, терроризм һәм экстре-мизмга каршы тору буенча даими агарту чаралары үткәрү максатында төзелә.

4. Эшче төркем үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында антитеррористик комиссия белән үзара бәйләнештә торып гамәлгә ашыра.

5. Эшче төркемнең бурычлары:

- терроризм профилактикасы өлкәсендә мәгълүматый сәясәт мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы антитеррористик комиссиясенә халык категориясен билгеләүгә юнәлтелгән тәкъдимнәр әзерләү;

-терроризма һәм экстремизмны кисәтү өлкәсендә әзерләнгән контрпропа-ганда мәгълүматый материалларның сыйфатын тикшерү;

-Кайбыч муниципаль районы хакимият органнарының терроризм һәм экстремизмны кисәтү өлкәсендә эшчәнлеген планлаштыру кысаларында мәгълүматый-пропаганда эше исемлеген төзү;

-терроризм һәм экстремизм белән бәйле хәлләр килеп чыкканда, оператив башкарыла торган комплексы чараларны эшкәртү һәм гамәлгә кую;

- терроризм һәм экстремизмга каршы агарту чаралары үткәрү буенча методик кулланмалар әзерләү.

6. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында терроризм һәм экстремизмга каршы тору буенча мәгълүмат-пропаганда эше алып баручы антитеррористик комиссия эшче төркеме турында Нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы тарафыннан раслана.

7. Эшче төркем :

- билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнарыннан һәм вазыйфаи затлардан Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында терроризм профилактикасы өлкәсендә мәгълүматый сәясәтне гамәлгә ашыруга бәйле мәгълүматларны сорарга;

- эшче төркем утырышларына оешма вәкилләрен һәм бәйсез экспертлар чакырырга хокуклы.

8. Эшче төркем рәисе:

- эшче төркем эшчәнлеген координацияли;

- эшче төркем утырышларын билгели һәм алып бара;

- эшче төркем карарларын имзалый.

9. Эшче төркем рәисе урынбасары рәис булмаганда яисә аның кушуы буенча эшче төркем рәисе вазыйфаларын башкара.

10. Эшче төркем сәркатибе:

- эшче төркем утырышларын алып бара һәм имзалый;

- эшче төркем әгъзаларына утырышлар үтү урыны һәм вакыты турында хәбәр итә;

- эшче төркемгә килгән мөрәҗәгатьләр һәм материалларның исәбен алып бара.

11. Эшче төркем утырышлары эшче төркем рәисе тарафыннан раслан-ган график буенча 3 айга бер тапкырдан да кимрәк булмаганча үткәрелә.

12. Эшче төркем утырышлары уздыру вакыты һәм көн тәртибе эшче төркем әгъзаларына утырыш үткәрер алдыннан кимендә 5 көн элек хәбәр ителә.

13. Эшче төркем утырышлары анда эшче төркемнең исемлек составының яртысыннан артыгы катнашса хокукый дип санала.

14. Утырышларга беркетмә төзелә, утырыш нәтиҗәләре буенча эшче төркемнең карарлары чыгарыла.

15. Эшче төркемнең карарлары утырышта катнашучыларның күпчелеге уңай тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

16. Эшче төркем карарлары кабул ителгәннән соң бер атна вакыт эчендә кызыксынучы оешмаларга җибәрелә.

17. Эшче төркем карарлары тәкъдим характерында.

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Башлыгының
2019е. «15» мартында чыккан
19 номерлы карарына
кушымта № 2

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында терроризм һәм экстремизмга каршы тору буенча мәгълүмат-пропаганда эше алып баручы антитеррористик комиссия эшче төркем составы**

| | |
|---|---|
| Макаров А.Н. | Эшче төркем рәисе, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Бикбова Ф.Ш. | Эшче төркем рәисе урынбасары, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Петухова Ф.Ф. | Эшче төркем сәркатибе, Кайбыч муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору буенча урынбасары |
| Хәмидуллин И.И. | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы |
| Аблязова Р.Р. | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы |
| Лотфуллина З.Ф. | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм буенча эшләр бүлеге башлыгы |
| Сөнгатуллина Л.М. | «Татмедиа» ААҖ филиалы «Кайбицкие зори» – «Кайбыч таңнары» газетасы редакциясенең директоры-баш мөхәррире |
| Воробьев С.Д. | Россия ЭЭМның Кайбыч районы буенча башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Лотфуллина Р.Г. | ТР Кайбыч муниципаль районы ветераннар Советы Рәисе |
| Гыйниятуллин Дамир хәзрәт | ТР Кайбыч районы имам -мөхтәсибе |
| Николай Атакай Ермолаев | ТР Кайбыч районы благочинные |

| | |
|---|---|
| Ермолаева Н.А. | "Гаилә кыйммәтләрен үстерү" - "Ышаныч, Өмет, Мәхәббәт" |
| Михайлов Ю.В. | «ФОРПОСТ» Үзәге директоры |
| Сайранов Р.Р. | «Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсенең Кайбыч бүлеге җитәкчесе |